| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**2017 елның 11 марты** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 466** |

2017 елда Зеленодольск муниципаль районы предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре тарафыннан җәмәгать эшләрен оештыру турында

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җәмәгать эшләрен оештыру турындагы нигезләмәне раслау турында» 1997 елның 14 июлендәге 875 номерлы карарын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 24 февралендәге 99 номерлы карарын үтәү йөзеннән, эшсезлекнең икътисади нәтиҗәләрен йомшарту һәм эшләмәүче халыкка өстәмә эш хакы рәвешендә матди ярдәм күрсәтү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2017 елда җәмәгать эшләре статусы бирелә торган Зеленодольск муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган эшчәнлек төрләре исемлеген расларга (1 нче кушымта).
2. Зеленодольск муниципаль районының предприятие, учреждение һәм оешмалары җитәкчеләренә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә (2 нче кушымта):

2.1. Зеленодольск шәһәренең Халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә һәр айның 1 числосына кадәр җәмәгать эшләре күләме буенча тәкъдимнәр җибәрергә ;

2.2. Зеленодольск шәһәренең Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге белән килешү буенча җәмәгать эшләрен оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә;

2.3. халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте тарафыннан җәмәгать эшләрен башкару өчен җибәрелгән гражданнарны эшкә урнаштыруны һәм үз вакытында хезмәт хакын түләүне гамәлгә ашырырга.

3. Зеленодольск шәһәренең халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә (С. В. Гататдиновага) түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

3.1. Зеленодольск муниципаль районы эш бирүчеләре тарафыннан игълан ителгән җәмәгать эшләренә эшсез гражданнарны оператив рәвештә җибәрүне тәэмин итәргә;

3.2. җәмәгать эшләрендә эшләүче эшсез гражданнарга матди ярдәм түләүләрен үз вакытында башкарырга.

4. ЗМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге башлыгына (А.Н.Коршуновка) әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны һәм сайтта урнаштыруны тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары С.В. Кадыйровага йөкләргә.

Җитәкче А.Х.Сәхибуллин

Татарстан Республикасы Зеленодольск
муниципаль районы
Башкарма комитетының
2017 елның «11» мартындагы
466 номерлы карарына
1 нче кушымта

**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ ҮТКӘРЕЛӘ ТОРГАН ТӨП ҖӘМӘГАТЬ ЭШ ТӨРЛӘРЕ ИСЕМЛЕГЕ**

- Авыл хуҗалыгының язгы кыр эшләрен башкарганда сезонлы эшләр
- Торак-коммуналь хуҗалыкны эксплуатацияләү
- Төзелеш материаллары җитештерү
- Территорияне җыештыру, төзекләндерү һәм яшелләндерү
- Ярдәмче эшләр
- Биналарга, корылмаларга хезмәт күрсәтү һәм төзекләндерү эшләре
- Икенчел чимал һәм калдыкларны җыю һәм эшкәртү
- Янгыннан соң урманнарны торгызу (кырку, кисү)
- Куаклар кисү, үлән чабу, территорияне чүп-чардан чистарту, чүп-чар чыгару эшләре
- Кар чистарту һәм шугалакларны су белән тутыру
- Квартал эчендәге территорияләрне һәм контейнер мәйданчыкларын чүп-чардан һәм көнкүреш калдыкларыннан санитар чистарту
- Торак йортлардагы бүлмәләрне, баскыч мәйданчыкларын җыештыру
- Автобус тукталышларын төзекләндерү һәм җыештыру
- Автотранспортны юу
- Архивларны оештыруда һәм карап тотуда ярдәм (архивка тапшыру өчен документлар әзерләү эшләре);

Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2017 елның «11» мартындагы
466 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Җәмәгать эшләрен**
**әзерләүдә һәм уздыруда катнашучылар**
**Зеленодольск муниципаль районы**
**предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары исемлеге**

1. « Уютный дом» ҖЧҖ
2. «Таиф»торак компаниясе» ҖЧҖ
3. «Респект» торак компаниясе» ҖЧҖ
4. «Бизнес-Үзәк» ҖЧҖ
5. « Энергосервис - Н»ҖЧҖ
6. «Жилсервис - М» ҖЧҖ
7. «Старт-3» ИК ҖЧҖ
8. « АДС»ҖЧҖ
9. « Восток-сервис»ҖЧҖ
10. «Карамалы Тау торак комсервис» МУП
11. «Экоресурс» ҖЧҖ
12. « Күгәй»СХПК
13. «Норлатстройсервис» ЯАҖ
14. Васильево штп БК
15. Карамалы Тау штп БК
16. Әйшә авыл җирлеге БК
17. Акъегет авыл җирлеге БК
18. Олы Ачасыр авыл җирлеге БК
19. Большие Ключи авыл җирлеге БК
20. Олы Шырдан авыл җирлеге БК
21. Олы Җәке авыл җирлеге БК
22. Бишнә авыл җирлеге БК
23. Олы Карагуҗа авыл җирлеге БК
24. Күгеш авыл җирлеге БК
25. Күгәй авыл җирлеге БК
26. Мамадыш-Әкил авыл җирлеге БК
27. Мулла Иле авыл җирлеге БК
28. Түбән Урысбага авыл җирлеге БК
29. Норлат авыл җирлеге БК
30. Октябрь авыл җирлеге БК
31. Осиново авыл җирлеге БК
32. Раифа авыл җирлеге БК
33. Өтәшкә авыл җирлеге БК